КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 6 сентябрь г.Казань № 821

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 31 октябрь, 965 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1262 нче; 2019 ел, 6 май, 380 нче; 2019 ел, 11 июль, 565 нче; 2019 ел, 28 август, 714 нче; 2019 ел, 2 ноябрь, 1008 нче; 2019 ел, 30 декабрь, 1278 нче; 2020 ел, 16 апрель, 294 нче; 2020 ел, 21 май, 413 нче; 2020 ел, 1 сентябрь, 772 нче; 2020 ел, 23 октябрь, 954 нче; 2021 ел, 26 июль, 645 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә, 3 нче таблицаның 4 – 7 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «4. | Авыл җирендә һәм шәһәр тибындагы поселокларда урнашкан рус булмаган телдә белем бирүче | педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | дүртенче | 5,0 |
| | | структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфалары | беренче – икенче | 5,0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | гомуми белем бирү оешмаларында рус телен 1 – 11 сыйныфларда һәм әдәбиятын 5 – 11 сыйныфларда укыту | | | |
| 5. | Авыл җирендә һәм шәһәр тибындагы поселокларда урнашкан рус булмаган телдә белем бирүче мәктәпкәчә төркемнәрдә балаларга рус телен өйрәтү | педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | өченче – дүртенче | 5,0 |
| 6. | Рус телендә белем бирүче гомуми белем бирү оешмаларында туган телне (татар, чуваш, мари һ.б., рус теленнән тыш) һәм әдәбиятны укыту | педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | дүртенче | 5,0 |
| | | структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфалары | беренче | 5,0 |
| 7. | Рус телендә белем бирүче мәктәпкәчә төркемнәрдә балаларга туган телне (татар, чуаш, мари һ.б., рус теленнән тыш) өйрәтү | педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | өченче – дүртенче | 5,0». |

2. Бу карар 2021 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин